Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Иске Шигали авылы Молодежная урамы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

15 декабрь, 2024 ел № 7

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Иске Шигали авылы Молодежная урамы гражданнары җыенының 2024 елның 15 декабрендәге беркетмәсе нигезендә карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1. статьясындагы 2 өлеше нигезендә, Шигали авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәнең 5 өлешендәге 5 пункты нигезендә түбәндәге мәсьәләләр буенча гражданнар җыены: «Сез 2025 елда Шигали авыл җирлеге Иске Шигали авылы Молодежная урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Молодежная ур.) » **узмаган дип санарга кирәк**.

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Шигали авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Шигали авыл җирлеге башлыгы В.М. Сәлимов